| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГОСЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2020 елның 18 декабереннән** **№ 14**

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 мартындагы 140 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 11 статьясындагы 5 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар.»

1.2. 1 нче кушымтаның 13 статьясындагы 3 пунктының 4 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;»

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм www.mendeleevsk.tatarstan.ru Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Песәй авыл җирлеге
Советы Рәисе В.И. Мөхәммәтгалиев